ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 сентябрь 2025 ел № 7503

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8503 номерлы Карары белән расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8503 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 25 апрелендәге 3367 номерлы, 2024 елның 4 мартындагы 1374 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча өстәргә:

«4) «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә видеоконференцэлемтә форматында электрон формада.»;

2) 2.13.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13.2. Гаризаны «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә видеоконференцэлемтә форматында электрон формада һәм/яки Бердәм, Республика порталлары аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм, Республика порталларының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүне раслаучы

белдерү кәгазе ала.»;

3) 3.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Бердәм, Республика порталлары аша электрон формада, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә видеоконференцэлемтә форматында электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.»;

4) 3.3.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2.1. Гариза бирүче Бердәм, Республика порталлары аша электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

- авторизацияләүне башкара;

- электрон гариза формасын ача;

- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

- электрон формадагы документларны яки документларның электрон рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

- электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм ризалык фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге куя);

- хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге куя);

- тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

- электрон гариза Регламентның 2.5.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

- электрон гаризаны җибәрү турында белдерү кәгазе ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасының һәр кыры тутырылганнан соң гамәлгә ашырыла. Гаризаның электрон формасының дөрес тутырылмаган кыры ачыклаганда, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: электрон хезмәттәшлек системасы аша Органга җибәрелгән электрон дело.»

5) түбәндәге эчтәлектәге 3.3.2.2 һәм 3.3.2.3 пунктлар өстәргә:

«3.3.2.2. «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы ярдәмендә гариза бирү өчен гариза бирүче:

- Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы (ЕСИА) ярдәмендә махсуслаштырылган программа тәэминатында авторизация уза;

- программа тәэминаты интерфейсы аша КФҮнең гаризалар кабул

итүче хезмәткәренә видешалтыратуны гамәлгә ашыра.

3.3.2.3. КФҮнең гаризалар кабул итүче хезмәткәре:

- гариза бирүче тарафыннан хәбәр ителгән мәгълүматларга һәм сайланган хезмәткә нигезләнеп, гариза бирүченең шәхесен идентификацияли;

- гаризаның электрон формасын тутыра, шулай ук Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларны соратып ала;

- гаризаны тикшерү һәм имзалау (раслау) өчен файл рәвешендә гариза бирүчегә тапшыра;

- раслаганнан соң гаризаны һәм документлар пакетын Органга җибәрә.

Шәхесне идентификацияләү гариза бирүченең йөзен паспорттагы фотография белән чагыштыру, шулай ук контроль сораугa дөрес җавап бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Сораштыру вакытында дөрес җавап бирелгән очракта шәхесне идентификацияләү уңышлы дип санала.

Гаризаның электрон формасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында билгеләнгән структурага туры килә.

Гариза бирүче тарафыннан автоматлаштырылган режимдагы система белән сайланган мәгълүмат бирү ысулы буенча гариза бирүчегә документлар кабул итү турында белдерү кәгазе җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: Органга җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов